Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы

РЕШЕНИЕ                                                                                    КАРАР
22.02.2023 ел                                                                                    №129

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 17 июнендәге 181 номерлы Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 04 ноябрендәге 423-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 17 июнендәге 181 номерлы Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 8 статьяда:

а) «Россия Федерациясе гражданнары» сүзләреннән соң атамасын « чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар сүзләре белән тулыландырырга»;

б) «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң беренче абзацны « чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар»сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны җирлек территориясендә урнашкан махсус билгеләнгән стендларда халыкка җиткерергә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе                                                                                    Р.Ә.Кәримов